

Үткән атнада «Заманча мәктәп» федераль милли «Мәгариф» проекты кысаларында Темников районы Аксел урта мәктәбендә «Үсеш ноктасы» дигән цифрлы һәм гуманитар профильле мәгариф үзәге тантаналы ачылды. Республикабызда быел шундый 27 үзәк эшлиячәк.

Бу шәһәр һәм авыл мәктәпләре арасындагы аерманы киметү очен булдырылган уникаль проект. Базаларында үзәкләр барлыкка килә торган мәгариф оешмалары жыелмасы федераль челтәрне тәшкил итә. Аларда белем бирүнен һәм тәрбия бирүнен, топ һәм остәмә гомуми белем бирү программаларын укучылар тарафыннан цифрлы, табигый-фәнни, техник һәм гуманитар профильләрне үзләштерүне тәэмин итә торган яна методларын, белем бирү технологияләрен барлык дәрәҗәләрдә гамәлгә кертү очен шартлар тудыру каралган. Үзәкнен топ бурычлары: «Технология», «Информатика», «Тормыш иминлеге нигезләре» кебек фәннәрне укыту методларынын эчтәлеген янарту һәм камилләштерү; халыкнын гомум-мәдәни компетенцияләрен һәм санлы белемнәрен, шахмат белемен, проект эшчәнлеген, балаларнын, педа-гогларнын һәм ата-аналарнын ижади момкинлекләрен үс-терү очен дәрестән тыш чорда инфраструктураны куллану.



Безнен мәгариф үзәгендә цифрлы һәм гуманитар профильле 5 хезмәткәр эшли: үзәк житәкчесе, информатика укытучысы П.В.Никитин, педагог-оештыручы, математика укытучысы Г.А.Тенишева, технология һәм ОБЖ укытучысы В.В.Глазунов, физик культура укытучысы А.Т.Шабров, остәмә белем бирү педагогы Т.В.Кузнецова, шахмат буенча Н.Н.Чибирев хезмәттәшлек итә-чәк. Бу эшкә башка педагоглар да жәлеп ителәчәк. Жәйге чорда, момкин булганча, ике кабинетта ремонт ясалды. Август-сентябрь айларында жиһазлар кайтарылды. Бүгенге кондә 75% ка якын жиһаз алынган. Әмма VR шлем, 3d принтер, мебель комплектлары - 15 парта белән 30 урындык килер дип котәбез. Бүген сезнен игътибарыгызга үзәк-нен ике кабинетын тәкъдим итәбез һәм безнен педагоглар әлеге проект кысаларында

